# БЕР ГЕНӘ МИНУТКА

*Фирзәр Мортазин көе*
*Динә Камалетдинова шигыре*

Бер генә минутка, барсын да оныт та,
Кил әле, кил әле янымa.
Ягымлы карашың кояштай карасын
Сагыштан әрнегән җаныма.

Тик сине эзлим мин, тик сине юксынам.
Бөтенләй югалтсам, нишләрмен?!
Кайларда йөрмәдем, сиңа тиң күрмәдем,
Гел сиңа ашкынды хисләрем.

Син тере шатлыгым, тормышым маягы,
Йолдыз син күңелем күгендә.
Бик соңлап кайтсаң да, кайчан да, кайчан
да,
Урының йөрәгем түрендә.